| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 Казан шәһәре № 10-23/кс

«Сток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен су бүлүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.04.2017 №10-9/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020 елга су агызуга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Сток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен су агызуга 2017-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 14.04.2017 № 10-9/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 №10-54/кс, 21.11.2018 №10-53/кс карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.04.2017 ел № 10-9/кс карарына 1 кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 10-23/кс карары редакциясендә)

Су агызуны гамәлгә ашыручы «Сток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен су агызуга 2017-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | карар гамәлгә кергән көннән башлап 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.07.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Кукмара муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Сток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 29,23 | 30,34 | 30,34 | 31,55 | 31,55 | 32,28 | 32,28 | 32,69 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.04.2017 ел № 10-9/кс карарына 2 кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 10-23/кс карары редакциясендә)

## Су бүлүне гамәлгә ашыручы «Сток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2017-2020 елларга су бүлүгә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Сток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Су агызу | 2017 | 6194,10 | 1 | - | - | 2,1 |
| | | 2018 | 6270,97 | 1 | - | - | 2,1 |
| | | 2019 | 6493,83 | 1 | - | - | 2,1 |
| | | 2020 | 6621,74 | 1 | - | - | 2,1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге